РАВИЛ КУЗЮРОВ:
«Балаларның урман белән кызыксынуын саклап каласы иде»
> 2

ЛАЕКЛЫ ХЕЗМӘТ
Казан дары заводына эшчеләр кирәк
> 3

ҖИҢҮ ТЕЛӘП
Тукай районының Биклән авылы халкы махсус хәрби операциядәге егетләргә булыша
> 4

МАРАТ КӘБИРОВ:
«Без ничектер бертөрлерәк бәндәләргә әверелеп беттек бугай. Бер үк сүзләр, бер үк эшләр...»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 106 (29073) | Чәршәмбе | 26 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЮЛЛАР ИГЪТИБАР СОРЫЙ,

ЯКИ ЯМЬЛЕ ҖӘЙНЕ ЯМЬСЕЗЛӘТМИК

Балалар катнашындагы юл һәлакәтләренең күпчелеге җәйге каникулга туры килә. Белгечләр әнә шундый күңелсез нәтиҗәгә килгән. Ямьле җәйнең ничек ямен җибәрмәскә? Белгечләр белән шул турыда сөйләштек.

Татарстан Дәүләт автоинспекциясе мәгълүматлары буенча, узган ел һәлак булган унбер баланың алтысы җәйге айларда харап булган. Быелның алты аенда исә 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 204 юл һәлакәте теркәлгән. Аларның бишесе үлем белән тәмамланган. 221 бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәт алган. Аварияләр саны узган елның шул чоры белән чагыштырганда – 5 процентка, ә зыян күрүче балалар саны 6 процентка артыграк.

– Әгәр атна көннәре белән карасак, балалар һәм яшүсмерләргә бәйле һәлакәтләрнең күпчелеге сишәмбегә туры килә. Авариягә исә барыннан да бигрәк 15–16 яшьлекләр эләгә, – ди Татарстан Дәүләт автоинспекциясенең юл хәрәкәте куркынычсызлыгын пропагандалау бүлеге җитәкчесе Рамил Әхтәмҗанов.

Билгеле, мондый юл һәлакәтләре күпчелек очракта машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыкса да, балаларның үзләренең саксызлыгы да аяусыз нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Мәсәлән, статистика мәгълүматларына күз салсак, быелның ярты елында шундый 54 һәлакәт теркәлгән. Аларның берсендә бер баланың гомере өзелгән.

– Гадәттә, мондый фаҗига баланың юлны дөрес урында чыкмавы аркасында килеп чыга. Яки юл кичүенә барып җитмичә, якыннан гына чыгарга теләгән бала да машина тәгәрмәче астында калырга мөмкин. Шулай ук авария кызыл утка яки юлга кинәт йөгереп чыгу аркасында да булырга мөмкин, – дип аңлата белгечләр.

Хәер, бәлагә җәяү йөргәннәр генә түгел, механик транспортта, велосипедта җилдергән балалар һәм яшүсмерләр дә юлыга. Әйтик, быелның ярты елында велосипедлы балалар катнашында 30 юл һәлакәте булган, аларның унсигезе баланың саксызлыгы аркасында килеп чыккан.

Бәла-каза балаларны шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да сагалап тора. Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылына

Илдар Мөхәммәтҗанов

да җәйге ялга балалар кунакка күп кайта. Урам тутырып йөрүчеләр арасында җәяүлесе дә, велосипед яки мопед иярләгәне дә бар. Авыл советы башлыгы Рөстәм Фәткуллин әйтүенчә, мопед белән хәрәкәт итүчеләр күбрәк тә әле.

– Велосипедта йөрүләр артта калып бара инде хәзер. Яшүсмерләрнең күпчелеге мопедта җилдерә. Менә анысы чыннан да проблема, – ди ул. – Үз авылыбызда укучыларның әти-әниләре белән профилактика үткәрелә, әллә шуңа да аларның балаларына бер әйтү дә җитә, ә менә шәһәрдән кайтучылар белән хәлләр авыррак. Аларны шелтә белән дә, кисәтү белән дә җиңеп булмый. Әти-әниләре дә, авылда барысы да ярый, балаларына бер куркыныч та янамый, дип уйлый. Ләкин авылда да юл йөрү кагыйдәләрен сакларга кирәк. Юлларга вак таш түшәлгән, мопед өчен куркынычрак, шулай ук машинасы да, башка техникасы да йөреп тора. Соңгы вакытта квадроциклллар да күренә башлады. Авыл эчендә генә түгел, авыллар арасында да йөри бит яшүсмерләр. Барысын да карап, барлап, артларыннан йөреп бетереп булмый. Һәр ата-ана үз баласына саклану кагыйдәләрен кат-кат әйтсен иде.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Рөстәм Гарипов әйтүенчә, юл кагыйдәләрен бозучы балаларга да, зурларга да иң нәтиҗәле чара – профилактика, дөрес юл йөрү кагыйдәләрен пропагандалау.

– Мондый чакта без халык белән төрле форматта эшлибез. Бу штраф кына түгел. Беренче чиратта, пропаганда. Кешеләр, шул исәптән балалар да ахыргы нәтиҗәнең бик аяныч булуын аңларга тиешләр. Без балаларга һәрвакыт гади генә мисал китерәбез: мәктәптә «2ле» алырга һәм аны аннан соң «5ле»гә төзәтергә мөмкин. Ә менә юлдагы хатаны төзәтеп булмаячак, ул бик аяныч нәтиҗәгә китерергә мөмкин, – ди Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Рөстәм Гарипов.

Психолог Ләйсән Гарипова да зурлар белән чагыштырганда, балаларда куркынычсызлык хисе азрак булуын әйтте. Чөнки аларда тормыш тәҗрибәсе юк.

– Балалар һәм яшүсмерләр күпчелек әйберләргә җиңел карый. Чөнки аларның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаган очраклар да ул дәрәҗәдә күп булмый әле, – ди ул. – Алар зурларга караганда гамьсезрәк. Шуңа күрә зурларның бурычы – баланың исән-имин булуы. Моны яки аны куркытып, яки билгеле бер шартларда, урыннарда үз-үзеңне саклау кагыйдәләрен өйрәтү юлы белән хәл итәргә мөмкин. Соңгы елларда балалар колакчын һәм телефон белән дә бик нык мавыга. Юл аша чыкканда да аларны читкә алып куймыйлар. Ә бу игътибарны тиешле тарафка юнәлтергә комачаулый. Колакка яңгырап торган көчле музыка тавышы әйләнә-тирәне адекват кабул итәргә ирек бирми һәм ориентир югала. Шуңа күрә әти-әниләр балаларына әледән-әле юл йөрү кагыйдәләрен искә төшереп торырга тиешләр.

Уңайлы яши башлаганнар

2019 елда «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм программасы гамәлгә кертелгәннән бирле, Татарстанда барлыгы 1762 кеше авария хәлендәге торагыннан яңасына күчкән. Территорияләрне үстерү фонды матбугат хезмәте хәбәренә караганда, республикада 12 муниципалитетның дүртесендә: Казанда, Актаныш, Балтач һәм Алабуга районнарында программа тәгәлләнгән дә инде. Кешеләрне күчерү өчен фатирлар яңа йортлардан сатып алынган. Әйтик, Казанда Илһам Шакиров урамындагы күпфатирлы йортка 281 кешене күчерү өчен барлыгы 121 фатир сатып алынган. Тагын 112 кеше Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров урамнарындагы йортларда урнашкан 108 фатирга күчкән.

Шунысы да бар: Татарстан – авария хәлендәге торакта яшәүчеләрне яңасына күчерүнең яңа ысулын кулланучы беренче төбәк. 2022 елда җиде шәхси йорт төзелеп, 22 кеше шуларга күченгән. Бу авылларда яшәүчеләргә уңайлы тормыш шартлары тудыру һәм эш урыннарын саклап калу мөмкинлеге биргән.

Икенең берсен сайлыйсы

Татарстанда федераль ташламага хокуклы 224654 кеше социаль хезмәтләр җыелмасын натуралата алып килә. Ягъни даруларны, медицина әйберләре, сихәтле ризыкларны бушлай ала, дәвалану урынына бушлай барып кайта, түләүле шифаханәләрдә бушлай дәвалана дигән сүз.

Ташлама инвалидларга, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, һәлак булган (вафат булган) хәрбиләрнең гаилә әгъзалары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, радиация һәм техноген һәлакәтләрдә зыян күрүчеләр, Ленинград камалышын кичерүчеләр, фашист лагерьларының элекке балигъ булмаган тоткыннарына бирелә.

Мондыйларга натуралата социаль хезмәтләр җыелмасы айлык акчалата түләү (ЕДВ) билгеләгәндә бирелә. Ташламаны акчага да алыштырырга мөмкин. Дөрес, акча күләменең хезмәт күрсәтү күләменә туры килмәве дә бар. Мәсәлән, дарулар, юллама һәм юл йөрү чыгымнары күпме кирәк, шулай бирелә. Ә менә акча билгеләнгән күләмдә генә (1132,03 сум) түләнелә. Татарстан Социаль фонды идарәчесе Эдуард Вафин аңлатып үткәнчә, ташламаны натуралата алу күпчелек очракта отышлырак. Мәсәлән, кыйммәтле дарулар таләп ителгән очракларга кагыла бу.

Социаль ярдәм чаралары рәвешен сайлап алу өчен 1 октябрьгә кадәр Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша Социаль фондның клиентлар хезмәтенә яки Күпфункцияле үзәккә гариза язып тапшырырга кирәк. Ташламалы хезмәтләр киләсе елның 1 гыйнварыннан гаризада билгеләнгән ысул белән күрсәтелә башлаячак.

Куркыныч иртә

25 июльдә Түбән Кама шәһәренең Вахитов проспекты, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан биш катлы йортта шартлау нәтиҗәсендә янгын чыккан. Беренчел мәгълүматлар буенча, янгынның сәбәбе – йортта яшәүчеләрнең көнкүреш газны саксыз рәвештә файдалануы. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе хәбәр итүенчә, 15 кеше урамга мөстәкыйль рәвештә чыккан, 9 кешене, шул исәптән бер баланы янгын күзәтчелеге хезмәткәрләре коткарган. Зыян күргән ике кеше – табиблар күзәтүе астында.

Шәһәр мэры Рамил Муллин шартлау нәтиҗәсендә фатирларына зыян килгән кешеләр өчен 12 номерлы мәктәптә вакытлыча урнашу урыны әзерләнгәнен хәбәр итте. Моннан тыш, зыян күрүчеләргә мэрия тарафыннан ярдәм күрсәтеләчәк. «Һәр гаилә белән элемтәдә торырга кирәк. Безнең бурыч – янгын салган зыянны юкка чыгарып, тиз арада монда яшәүчеләрне үз фатирларына кайтару», – дигән Рамил Муллин районның гадәттән тыш хәлләрне юкка чыгару комиссиясенең ашыгыч киңәшмәсендә.

Каты чирлиләр

Республикада коронавирус йоктыручыларны хастаханәләргә салу очраклары янә арткан. 17–23 июль чорында барлыгы 33 кеше дәвалау учреждениесенә эләккән. «Реальное время» хәбәр иткәнчә, алдагы атнадагыга караганда бу сан 1,43 тапкыр күбрәк. 10–16 июльдә ковидлы 23 кеше (алдагы атнадагыдан 34 процентка кимрәк) хастаханәгә озатылган булган. Ә инде 3–9 июль арасында 35 кешегә (алдагы атнадагыдан 25 процентка артык) хастаханәдә дәвалану таләп ителгән.

Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда COVID-19 йоктыруның барлыгы 206537 очрагы теркәлгән. Шуның 59ы – 17–23 июльдә. 204388 кеше савыккан, 2010ы вафат булган.

Вазгыять

Абитуриент көтә

УКУ ЙОРТЛАРЫНДА ДОКУМЕНТЛАР КАБУЛ ИТҮ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

Кичә югары уку йортларында бюджет бүлегенә документлар тапшыруның соңгы көне иде. Абитуриентлар кайсы уку йортларын сайлаган? Имтиханнарда югары балл туплаган яшьләрне нәрсә белән кызыксындыралар? Без республика вузларындагы вазгыятьне белештек.

Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальков белдергәнчә, быел бюджет урыннарына 600 мең урын бүлеп бирелгән. Бу – бик зур сан. Уку йортларына керүчеләрнең 67 проценты бушлай укый алачак дигән сүз. Сүз уңаеннан, республиканың югары уку йортларында 20844 бюджет урыны бар.

Быел илнең яңа төбәкләреннән тыш, барысында да вузга җыенучылар өчен документларын «Поступи Онлайн» сервисы ярдәмендә тапшыру мөмкинлеге тудырылган. Гаризаларның яртысыннан артыгын яшьләр шуның аша биргән.

– Кабул итү кампанияләрендә хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстенлек бирелде. Андыйлар махсус ташламалардан файдалана ала. Әгәр кемнедер кабул итмәгәннәр икән, министрлык һәр шикаятьне аерым карарга әзер. Моның өчен гаризада исем-фамилия, вуз исемен һәм юнәлеш төрен күрсәтергә кирәк, – ди Валерий Фальков.

Абитуриентлар исә нәтиҗә көтә. Бәхет елмаермы, юкмы – анысы билгесез. Әмма БДИны яхшы балларга тапшырганнарның өмете зур. Барысының да укырга керү-кермәвен тизрәк беләсе килә.

– Мин документларны төрле вузларга тапшырдым. Шул исәптән Мәскәүгә дә. Конкурс нәтиҗәләрен күзәтеп барам. Мөмкинлекләр кечкенә түгел. Әмма минем КАИга кереп, инженер-технолог белгечлеген аласым килә. Анда очкычларны проектлау кафедрасына да гариза бирдем. Өч фәннән БДИда 217 балл җыйдым. Туган яктан, өйдән бер дә еракка китәсе килми, – ди Тәтеш районының Олы Тархан мәктәбе укучысы Далер Ситдыйков.

Далер мәктәптә башта – физика, аннан химия белән кызыксынган. Төрле олимпиадаларда катнашкан, җиңүләр яулаган. «Дөресен генә әйткәндә, 7 нче сыйныфка кадәр миңа уку кирәкмәде. Башымда бары компьютер уеннары гына иде. Аннан миңа ничектер фән өлкәсе, тәҗрибәләр ясау кызык тоела башлады», – ди егет.

Аксубай районының Иске Тимошкино мәктәбе укучысы, физикадан 100 балл туплаган Егор Симухинның да хәлен белештек. Әмма ул укырга кая керергә җыенуы турында сөйләргә ашыкмады.

– Мин бит әле укырга кермәдем. Конкурс нәтиҗәләрен көтәм, – диде Егор. (Югыйсә БДИдан 288 балл туплаган үзе. Әле бит бер фәннән 100 баллы да бар. Әмма шуңа да карамастан, бик ышанып җитми, ахры. Бәлкем, алдан кычкырырга теләмидер). – Әлегә барысы да сер булып калсын.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Александр БАСТРЫКИН, Россия Тикшерү комитеты башлыгы:

Блогерларның салым түләүдән качуына юл куярга ярамый. Икътисадый җинаятьләр – җитди проблема. Кайберәүләр Россиядә миллионнар эшли, шул ук вакытта дәүләткә бер тиен дә бирми.

(«РИА Новости»)

РОССИЯДӘ – САТЫП АЛУЛАР

«Русский стандарт» банкы оештырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, Россиядә яшәүчеләрнең интернет сатып алуларга кызыксынуы кимегән.

САТЫП АЛУЛАР
56% >> офлайн сәүдә
44% >> онлайн сәүдә

ОФЛАЙН САТЫП АЛУЛАР
Уртача чек >> **1312 сум**
Чагыштыру өчен:
2022 елда >> **1038 сум**



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЭШКӘ КЕШЕ КАЯН ТАБАРГА?

Бөтендөнья кризисының бу соңгы фазасы алдагы кризисларда күрелмәгән үзенчәлеккә ия: икътисадый яктан зур үсешкә ирешкән илләр демографик упкынга мәтәлеп баралар. Нәтиҗәдә эшкә кеше табу кыенлаша. Европа илләре һәм АКШта эшче куллар кытлыгы бик сиздерми, чөнки проблеманы мөһаҗирләр хәл итә. Мигрантларга чикләрен бикләп торган Япониядә исә эшкә кеше яллау зур кыенлыкка әверелеп килә. Бу атна башында япон Премьер-министры Фумио Кисида Токиода да проблеманы хәл итүнең тапталган ысулын кулланырга ниятләүләрен белдерде. «Безгә чит ил кешеләре белән янәшә яши торган җәмгыять турында уйларга кирәк була, – диде ул. – Чит ил кешеләрен яшәргә кабул итү моннан соң зур бурычка әвереләчәк». Илдә халык саны кимү һәм милләтнең картаюы проблемасын хәл итү өчен мигрантларны чакыру программасы яңадан әйләнеп кайта. Бу юнәлештә берничә ел элек беренче адымнар ясала башлаган иде инде, әмма коронавирус пандемиясе, чикләрне бикләп, проектны туктатып торды. Хәзер вазгыять нормальләште һәм Токио үткәндәге планнарга әйләнеп кайтырга ниятли.

Бүгенге Япониядә 125 миллион тирәсе кеше яши. Даими рәвештә 3 миллионнан бераз артыграк чит ил кешесе дә тормыш алып бара. Хакимиятләр югары квалификацияле мөһаҗирләргә озак сроклы һәм даими яшәү хокукын бирүне җиңеләйтергә җыеналар. Андый хокукны тагын шәфкать туташлары һәм бала тәрбияләүчеләр, төзелештә һәм авыл хуҗалыгында, кораблар төзүдә эшләүчеләр дә җиңел ала башларга тиеш.

Мөһаҗирләр белән шыплап тулган Төркиядә дә эшкә кеше табу кыен икән. Илнең Сәүдә палатасы президенты Гөрсел Баран: «Эш бирүче, миллионлаган лира акча тыгып, бизнес ача, әмма бу бизнес өчен кешеләр табу проблемасы алдында көчсез кала», – дип белдерә. Шунысы кызык: Төркиядә рәсми эшсезлек 9 процент дип исәпләнә. Бу санны зур түгел дип санийлар. Шул ук вакытта йөз меңләгән мөһаҗир эшкә урнаша алмый, чөнки махсус рөхсәте булмаган чит ил кешесен эшкә алса, эшмәкәр зур күләмдә штраф түли. Мигрантларга эшкә урнашу хокукы алу җиңел түгел. Төрекчә эшче куллар кытлыгын бөтенләй башка проблема тудыра. Эшкә урнашырга теләүчеләр күп, әмма бизнес аларны канәгатьләндерерлек акча түләми. Эш эзләүчеләрнең өметләре безнең ил чынбарлыгына туры килми, диләр төрекләр үзләре. Эре сәүдә бизнесы 150 процентлык, нефть-газ тармагы хуҗалары 230дан алып 1000 процентка кадәр табыш ала, ләкин эшчеләргә минималь хезмәт хакыннан артык түләми, ди бәйсез төрек аналитиклары. Андый хезмәт хакына тир түгәргә теләүчеләр күп түгел, чөнки илдә инфляция котырына, тормыш алып бару кыен. «Илнең эчке тулай продуктында хезмәт хаклары өлеше 34 процент кына, хәтта сугышучы Россиядә дә бу сан – 50 процент», – дип зарлана алар.

Россиядә

ЕРАК КӨНЧЫГЫШ КЫТЛЫГЫ

Эшче куллар дефициты без яшәгән илдә дә төп проблемаларның берсенә әверелеп бара. Ташкичү фермасында төп эшче көчләр – таҗик егетләре. Элекке буын сыер савучылар пенсиягә чыгып бетү сәбәпле, эшкә уртаазиялеләрне җигәргә туры килде. Югыйсә сыерларның баш санын киметергә кирәк булачак иде. Мөгаен, киләчәктә тракторчы-комбайнчыларны да чит илдән эзләргә туры килер.

Россия төбәкләреннән Ерак Көнчыгышта проблема аеруча зур. Бу көннәрдә анда федераль хөкүмәт җитәкчесе Мишустин рәсми визит белән килде. Югары түрәләр төбәкне инвестицияләр өчен кулай дип саный. Әмма төбәк халык санының кискен кимүеннән интегә. Мишустин, Владивостоктан торып: «Приморье крае, Сахалин инвесторлар киләчәк урынга әверелделәр», – дип белдерде. Бу төбәкләрдә тормыш дәрәҗәсе илдәге уртача тормыш дәрәҗәсеннән югарырак булырга тиеш – дәүләт стратегиясе шундый. Премьер-министр фикеренчә, бу – бик зур һәм катлаулы мәсьәлә, әмма чишеп булырлык. Приморье краена ясалган гомуми инвестицияләр күләме 590 миллиард сумга җитә, күпсанлы эш урыннары булдырылган инде, тагын 170 мең урын булдырылырга тиеш. Планлаштырылган инвестицияләр күләме исә – 2,8 триллион сум. Хөкүмәт төбәкләрнең үсешен дүрт параметр буенча билгеләргә җыена: эчке төбәк продукты, инвестицияләр саны, эш урыннары саны һәм халыкның реаль керемнәре. Ерак Көнчыгыш федераль округында беренче өч параметр яхшы үтәлә икән. Әмма соңгы критерий белән эшләр мактанырлык түгел. 2022 елда реаль керемнәр 1 процентка кимегән, 2023 елның беренче кварталында 0,9 процентка гына арткан. Хезмәт хакларының номиналь күләме әйбәт үсә ул үсүен. 2019 елда 46,8 мең сумлык хезмәт хакы 2022 елда 63,5 мең сумга җиткән, пенсияләр 15,1 мең сумнан 19,6 мең сумга күтәрелгән. Ләкин керемнәрне инфляция кимерә. Аңлашыла инде: Ерак Көнчыгыш федераль округыннан кешеләр күпләп күчеп китә. Соңгы утыз елда анда халык саны 1,3 тапкыр кимегән. Ел саен кимү күләме 0,3–0,5 процент, ди рәсми документлар. Төбәкне хәтта мигрантлар да ташлап китә. 2019 елда 80,4 мең мөһаҗир килгән, 79,7 меңе киткән. Зур бер төбәккә мигрантлар бары тик 700 кешелек кенә үсеш биргәннәр. Халык саны кимү бөтен ил буенча кызу темплар белән бара бит инде. Ерак Көнчыгышта соңгы елларда демографик кризис темплары илдәге уртача күрсәткечләр белән тигезләшә башлаган. Шуны уңышка санийлар.

Хөкүмәт инвестицияләр ясый, зур акча тыга. Эшче куллар кытлыгы бу тырышлыкларны юкка чыгара ала. Японнар үз чикләрен ачып, эшкә кеше чакыра башласа, вазгыять тагын да начарая ала, чөнки уңайрак мөмкинлекләр янәшәдә генә пәйда булырга мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Абитуриент көтә

УКУ ЙОРТЛАРЫНДА ДОКУМЕНТЛАР КАБУЛ ИТҮ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Казан илкүләм тикшеренүләр технологик университетның (КХТИ) матбугат үзәгендә хәбәр итүләренчә, уку йортында 29 меңнән артык гариза кабул иткәннәр. Абитуриентларны бигрәк тә IT һәм нефть химиясенә бәйле юнәлешләр кызыксындыра. Әйтик, «Мәгълүмат системалары һәм технологияләре» юнәлешенә бер урынга – 33, ә «Нефть-газ эше» буенча 30 кеше дәгъва кыла. Бу сан әле артырга да мөмкин. Ни өчен дигәндә, без белешкәндә, төш вакыты иде. Ә документларны 25 июльдә төнге сәгать 12гә кадәр кабул итәләр.

– БДИны яхшы тапшырган абитуриентларга югары стипендияләр каралган. 240–259 балл җыйган егет-кызлар айга – 6600 сум, 260–279 баллы студентлар исә 8800 сум алырга мөмкин. Олимпиада җиңүчеләре һәм призерларына, шулай ук сынауда 280нән югары балл туплаучыларга 15 мең сум түләнә, – диделәр матбугат үзәгендә.

Казан дәүләт энергетика университетында исә кабул ителгән гаризалар саны – 5 меңнән артык. Монда «электроэнергетика һәм электротехника», «җылылык энергетикасы һәм техникасы», IT юнәлешләр популяр.

Әлеге университетта сынауны яхшы нәтиҗәләргә тапшырган барлык яшьләр дә пачутта. Кабул итү комиссиясендә өч имтиханнан 195 һәм аннан югары баллы яшьләрне көтәләр.

– Без югары балл җыючылар өчен кызыксындыру чаралары булдырдык. Балл күләменә карап, өч семестр дәвамында 5тән 16 мең сумга кадәр акча биреләчәк. Бөтенроссия олимпиадалары җиңүчеләрен имтихансыз кабул итәбез. Аларга ике ел дәвамында ай саен 30ар мең сум акча түләнә, – диде университетның беренче проректоры Александр Леонтьев.

Анда БДИны яхшы биргән, түләүле бүлектә укучы абитуриентларны да онытмаганнар. Аларга ай саен 4–10 мең сум стипендия тәтергә мөмкин. Моннан тыш, югары баллы абитуриентлар ректорның грантына дәгъва кыла ала. Биш җиңүчене вуз хисабына бушлай укытырга вәгъдә итәләр. Шулай ук тулай тороктан үзләре теләгән бүлмәне сайлау мөмкинлеге дә тудырылган. Вузга аттестатның төп нөсхәсен китерүчеләргә уку йортының символик тамгаларын, брендлы әйберләрен тапшыралар.

27 июльдә вузларның сайтында конкурс нәтиҗәләре буенча укырга керүчеләрнең исемлеге урнаштырылачак. Тагын ун көннән укырга кергән барлык студентларның исемлеге эленәчәк. Түләүле бүлекләргә документ кабул итү 20 августка кадәр дәвам итә.

Сәрия МИФТАХОВА

БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!

Җәйге ял

Ял эзләп ерак барасы түгел. Татарстанда яшәүчеләрне дә... Татарстанда ял итәргә чакыралар. Күрсәтерлек һәм карарлык, кызыктырырлык һәм кызыгырлык җирләребез күп, ди.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Алдан ук кисәтеп куярга кирәктер: сүз әлеге дә баягы Казан Кирмәне, Болгар һәм Зөя утравы турында бармаячак. Аларның туристларны җәлеп итү нокталары булуын һәркем белә инде. Ә республика эчендә тагын ниләр бар?

Хәзер күпләрнең теленнән глэмпинг (табигать кочагында кунакханә шартларында ял. – **Авт.**) дигән сүз төшми. Татарстанда да андый корылмаларның саны ишәя. Соңгы мәгълүматлар буенча, республиканың 16 районында шундый 42 заманча объект (глэмпинг, кемпинг, эко-кунакханә, ял базалары) бар. Алар 1,7 мең урынга исәпләнгән.

Андый корылмаларны сафка бастыруда, билгеле, инвестицияләр җәлеп ителә, эшмәкәрләр үзләре дә тырыша. Бюджет акчасы да иш янына куш булып тора.

Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов әйтүенчә, 2022 елда глэмпингларны сафка бастыру өчен 217,1 млн сум акча бүлеп бирелгән. Шуларның 219,6 млн сумы – федераль бюджеттан. Субсидиядән Татарстанның 10 районындагы 18 объект файдалана алган (Бөгелмә, Югары Ослан, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Менделеевск, Питрәч, Саба).

2023 елда исә шәһәр читендәге ял объектлары өчен пляжлар төзүгә субсидияләр бүлеп биреләчәк икән. Әлеге эш өчен 177,6 млн сум акча юнәлдереләчәк. Шуның 143 млн сумы – федераль акча. Хәзергә 14 проект әлеге матди ярдәмнән файдалана алган.

Татарстан территориясендә мондый урнашу объектлары барлыкка килү – әйбәт күренеш, билгеле. Бу туристларны җәлеп итү ысулы да, районнарга кызыксынуны арттыру да бит. Сергей Иванов әйтүенчә, андый эш белән шөгыльләнүчеләргә ярдәм итеп торырга гына кирәк.

– Районнарыбыз матур, тарихыбыз бай, күрсәтерлек җирләребез байтак, дип, озак һәм күп итеп сөйли алабыз инде без. Әмма бит районнарда төн кунарлык урыннар юк. Йә инде алар бар, әмма шартлары начар, – диде комитет башлыгы. – Яңа объектлар сафка басуга, шартлар да барлыкка килә.

- Day by day хезмәтендә теләге булган һәр кеше Татарстан буенча үз маршрутын тәкъдим итә ала. Яисә инде тәкъдим ителгәннәрен сайлап, сәяхәткә кузгалырга мөмкин.
- visit-tatarstan.com сайтында республикада кайда ял итәргә, нәрсә ашарга, нәрсә сатып алырга, нишләргә дигән сорауларга җавап табарга була.
- 2022 елда Татарстанда 3,9 млн кеше кунак булган иде. Быел бу сан 4 миллионга җитәр дип фаразлыйлар.
- Татарстанда ял итәргә уйласагыз, #ОТДЫХАЮВТАТАРСТАНЕ промокодын кулланырга онытмагыз. 5 процент ташлама ясаячаклар. Бу промокод 34 ял объектында гамәлдә.

P.S. *Гомумән, ял хакында әледән-әле язып торабыз. Ишетмәгән, күрмәгән, укымаган булсагыз, «ВТ» узган җомга санында җанга рәхәт, ә кесәгә отышлы булган ял төрләре турында язып чыккан иде. Җәй бетмәгән бит әле. Файдалы киңәшләрне кабат хәтерегездә яңартсагыз була, дибез инде.*

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Зөлфия ЛАТЫЙПОВА, Баулы шәһәренең «Салават күпере» ял һәм туризмны оештыру үзәге директоры, «АулДаЯл» этноглэмпингын оештыручы, Татарстанның авыл туризмы төбәк ассоциациясе рәисе:

– Палаткалы лагерьлар оештыру белән берничә дистә елдан артык шөгыльләнәм. Туризм темасы миңа ят түгел. Шуңа күрә глэмпинг эшен моның дәвамы дип саныйм. Безнең глэмпинг Исергәп авылында урнашкан. Этноглэмпинг санала ул. Моннан тыш тагын ике авылда ял базабыз бар. Алардан да халык өзелми.

Төп проблемаларга килгәндә, алар билгеле. Һәр кешегә нәрсә җитми? Акча җитми. Тагын бер авырткан җиребез – белгечләр. Гидлар, кунакларны каршы алучы, алар белән сөйләшә белүче белгечләр кирәк. Туристларның көйсезлегенә түзүчеләр! Акча безгә шундук һәм хәзер кирәк инде. Әмма сабырлык белән эшләргә кирәк. Акча өелеп төшми. Мин туристик үзәгемне ачканда берүзем генә идем. Блокнотыма: «Минем «мин» бар, без булдырабыз!» – дип язып куйганмын. Хәзер исә командам бар. Улым да туризм юнәлешендә белем алды. Ул булыша. Тирә-юнемдәге кешеләр булмаса, мин бу эшне үзем генә алып бара алмас идем. Проблемалар без бу җирдән киткәч тә кала ул. Мин үзем – бу җәһәттән оптимист. Зур планнар белән яшим.

Яшел байлык

УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЫ РАВИЛ КУЗЮРОВ:

«МӘКТӘП УРМАНЧЫЛЫКЛАРЫ САНЫН АРТТЫРАСЫ ИДЕ»

Балаларда кечкенәдән урманга карата игътибар тәрбияләү мөһим. Алар табигатьне саклауга үзләренең өлешләрен кертә. Мәктәпләрдә урманчылыклар да шул максаттан оештырыла. Июль азагында исә Лубян урман-техник көллиятендә мәктәп урманчылыклары слеты узачак. «ВТ» хәбәрчесе Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил КУЗЮРОВ белән республикадагы мәктәп урманчылыклары эшчәнлеге турында сөйләште.

:: Рафил Әфрәимович, Татарстанда мәктәп урманчылыгы хәрәкәте ничек эшли? Киләчәктә аны үстерү өчен нинди эшләр планлаштырыла?

– Республикада мәктәп урманчылыклары берләшмәләре 1968 елда оештырыла башлый. Алар арасында – Кукмара районының Лубян урта мәктәбе, Саба районының Лесхоз урта мәктәбе һәм Зәй районының 5 нче урта мәктәбе каршындагы мәктәп урманчылыклары. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге берләшмәләр хәзер дә эшли.

> Мәктәп урманчылыклары – үсеп килүче буынга экологик белем, һөнәри юнәлеш бирүнең һәм үзбилгеләнүнең нәтиҗәле формасы. Без бу өлкәдә актив эш алып барабыз. Чагыштыру өчен: 2018 елда Татарстанда 50 мәктәп урманчылыгы булган, ә хәзерге вакытта аларның саны 149га кадәр җитеп, 1,9 меңгә якын баланы берләштерә.

Саба районы – әлеге юнәлеш буенча һичшиксез лидер, анда һәр гомуми уку йортында мәктәп урманчылыгы бар. Районда барлыгы 26 берләшмә эшли, шуларның 20се быел оештырылган.

Без исә үзебезгә мәктәп урманчылыкларының санын берничә тапкыр арттыру максаты куйдык. Министрлык мондый берләшмәләргә йөрүче балалар белән эшләү сыйфатын, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча да эшли. Без заманча белем бирү программаларын эшлибез, аларның яңа төрләрен һәм форматларын эзлибез. Безнең бурыч – балаларның урманга булган кызыксынуын саклап калу, аларның сәләтләрен ачу һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

:: Мәктәптә «урманчылык» булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?

– Мәктәп урманчылыгының уңышы күбесенчә ике кызыксынган кеше – педагог һәм урман хуҗалыгы белгеченнән тора.

Әгәр дә балалар белән шөгыльләнергә әзер кешеләр бар икән, килешүләр, эш планнары төзү, программалар әзерләү – инде техник бурыч кына.

Без үз ягыбыздан һәртөрле ярдәм күрсәтергә әзер. Безнең белгечләр мәктәп урманчылыклары җитәкчеләре һәм кураторлары белән даими элемтәдә торалар, консультацияләр һәм методик киңәшләр бирәләр.

:: Ә мәктәп урманчылыкларына йөрүче балалар киләчәктә үз язмышларын урман хуҗалыгына бәйлиме соң? Яшь белгечләргә ярдәм чаралары каралганмы?

– Статистик мәгълүматларга караганда, мәктәптә шуның белән кызыксынган 20 кешенең берсе булса да урман профилендәге уку йортына укырга керергә карар итә һәм алга таба урман хуҗалыгында эшли.

Урманчы белгечлегенә Лубян урман-техник көллиятендә һәм Казан дәүләт аграр университетының урман хуҗалыгы һәм экология факультетында укырга мөмкин. Көллияттә «урман һәм урман-парк хуҗалыгы», «бакча-парк һәм ландшафт төзелеше», «икътисад һәм бухгалтерлык исәбе» юнәлешләре буенча укыталар. Университетта «урман эше», «ландшафт архитектурасы», «экология һәм табигатьтән файдалану» юнәлешләре бар.

> Татарстанда яшь белгечләргә ярдәм чаралары каралган. Ул урман профиле буенча белем йортларын тәмамлаган 30 яшькә кадәрге яшь белгечләргә бирелә. Финанс ярдәме күрсәтү турында килешү төзелгәннән соң кимендә өч ел эшләү шарт. Һөнәри белем бирү йортын тәмамлаган яшь белгечләргә – 150 мең сум, югары белем бирү йортын бетереп эшкә килүчеләргә бер тапкыр 300 мең сум күләмендә акча бирелә.

Министрлык урман белгечләренең хезмәт шартларын яхшырту буенча да системалы эш алып бара. Шул исәптән хезмәткәрләрнең эш хакларын арттыру буенча да. Моңа өстәп, ел саен техника паркы яңартыла, республика программасы кысасында безгә караган оешмаларның биналары ремонтлана, эшкә инновацияләр һәм фәнни казанышлар кертелә. Без яшь белгечләрне урман хуҗалыгына җәлеп итү өчен мөмкин булган барлык чараларны да күрәбез.

:: 26–28 июльдә Лубян урман-техник көллияте базасында мәктәп урманчылыкларының «Халык традицияләрендә – урман» VI слеты узачак. Шул хакта да сөйләгез әле.

– Слет мәктәп урманчылыклары хәрәкәтен үстерү программасы һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында үткәреләчәк. Анда 31 мәктәп урманчылыгыннан 93 кеше катнашачак, форум барлыгы 200 кешене җыячак.

Беренче көнне «Цифрлы урман викторинасы» интерактив интеллектуаль уены үткәреләчәк, аның барышында укучылар үзләренең эрудициясен, логикасын һәм тапкырлыгын күрсәтәчәк. Моннан тыш, Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган музыкаль-күңел ачу программасын оештыру да планлаштырыла.

Икенче көнне, 27 июльдә, мәктәп урманчылыкларының «Халык традицияләрендә – урман» VI слетын һәм «Яшь урманчылар» төп конкурсын ачу тантанасы булачак. Катнашучыларга эссе язарга һәм урманчылык хезмәтенә кагылышлы төрле юнәлешләр буенча гамәли биремнәр үтәргә туры киләчәк.

Шулай ук бу көнне «Рослесинфорг» федераль дәүләт учреждениесенең Казан филиалы, «Рослесозащита» филиалы – Татарстан Республикасы Урманнарны саклау үзәге һәм «ВНИИЛМ» филиалы булган Көнчыгыш Европа урман сынау станциясенең әйдәп баручы экспертларыннан белем бирү программалары оештырылачак. Укучылар урман планшетларын күрә алачак, электрон микроскоплардан файдаланырга өйрәнәчәк һәм урман өлкәсендә соңгы фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләре турында беләчәк. Шул ук вакытта урман янгыннарын сүндерү, сәнгатьле рәсемнәр ясау, туздан үрү һәм башка кызыклы мастер-класслар үткәреләчәк.

28 июль көнне исә слет җиңүчеләрен бүләкләячәкләр.

АЛТЫН УТТА СЫНАЛЫР

Һөнәр иясе

Казан дары заводы башкалардан нәрсәсе белән аерыла икәнен беләсезме? Эшчеләре белән үзенчәлекле ул. Бу хакта әле күптән түгел генә заводның 235 еллыгын билгеләп үткәндә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та әйтте. Завод хезмәткәре кем ул? Эш нәрсәсе белән кызыклы? Бу хакта завод хезмәткәрләренең үзләреннән сорадык.

«Хезмәтемнән тәм табып эшләдем», – ди кырык елдан артык гомерен Казан дары заводына багышлаган Социалистик Хезмәт Герое Легия Мөхәммәтҗанова. Үзе генә түгел, якыннары, туганнары да биредә хезмәт иткән һәм хәзер дә шушы юлны дәвам иттерә. Яушевлар – Әхмәдуллиннар – Мөхәммәтҗановлар – Романичевлар – Вәлиевләр хезмәт династиясенең гомуми стажы 320 ел тәшкил итә. Сүз уңаеннан, заводта 160 хезмәт династиясе исәпләнә.

– Әтием белән әнием икесе дә дары заводында эшләде. 1939 елда укып бетереп бирегә килгәннәр дә, шунда танышып, кавышып, хезмәт юлын бергә дәвам иткәннәр, – дип искә ала Легия апа. – Без гаиләдә сигез бала үстек, иң олысы – мин. Балачагыбыз Бөек Ватан сугышына туры килде. Хәтерлим, дары заводында эшләгәч, әти белән әнине сугышка алмадылар, бронь бирделәр. Әмма алар өйгә кайтып та кермәде диярлек. Көнне төнгә ялгап, илебез, Ватаныбыз хакына хезмәт иттеләр. Без, бала-чага да, бу эшнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен аңлый идек. Безнең белән бергә яшәгән дәү әниебезнең: «Чү, әти-әниегез кайтыр вакыт җитә», – дип бер әйтүе җитә, бөтен эшне тиз генә башкарып куя идек. Дәү әниебез бик тәрбияле, белемле кеше иде безнең. 1944 елда мәктәпкә укырга кердем. Ун сыйныф белем алгач, укытучы буласым килгән иде. Болак буендагы Педагогика институтының ишек төткасына кадәр ике бардым. Тик: «Ярар, кабат килермен әле», – дип кире борылып киттем. Өлкән бала булгач, җаваплылык хисе дә зур булгандыр инде, күрәсең. Үз йортыбыз белән яшәдек. Гаиләдә миннән кала җиде бала, дәү әни дә бар. Акча эшләргә кирәк, дигән уй заводка алып килде. Әти-әнием каршы килмәде. 1954 елның сентябреннән эшли башладым. 1992 елга кадәр, читкә китмичә, эшемә тугры калып, лаеклы хезмәт юлы уздым.

Легия апа кечке техникум тәмамлаган. Башта мастер, аннары өлкән мастер итеп билгелиләр үзен.

– Участок җитәкчесе урынбасары дәрәҗәсенә кадәр үстем, – дип искә ала 88 яшьлек Социалистик Хезмәт Герое. – Заводта хезмәткәрләр өчен тиешле шартлар тудырылмаса, болай эшләп тә булмас иде. Без барыбыз да бер гаилә кебек. Әле хәзер, эштән киткәч тә, заводтагы танышлар очраса: «Легия апа, ни хәлең бар?» – дип килеп кочаклап алалар.

«Әллә мин яхшы эшләгән, әллә җитәкчелек әйбәт булган инде шунда», – ди мәзәкләп Легия апа дәрәҗәле бүләк алуы турында.

– Ул вакытта демонстрацияләрдә катнашу, кем әйтмешли, ихтыяри-мәҗбүри иде бит. Хәтерлим, 1971 ел. Шулай урам буйлап демонстрациядә барабыз. Завод идарәсе яныннан узганда, юлда туктаттылар да, хәзер завод директоры чыга, диделәр. Ул арада идарәдән җитди киенгән өч-дүрт кеше күренде. «Төнгә каршы гына Хөкүмәт бүләге тапшыру турында телеграмма килде», – дип, мине бөтен кеше алдында котлап киттеләр. Соңрак медален дә тапшырдылар. Ул вакытта үзебезнең арада андый зур бүләк алучылар турында ишеткәнем дә юк иде, – ди Легия апа. – Хезмәтемә әнә шундый зур бәя биргәч, җаваплылык та артты, билгеле. Йөзәр кешелек бригада белән идарә итәргә туры килде. Шөкер, барысы да хөрмәт итте. Иң мөһиме – хезмәттәшләреңне тыңлый, аңлый белергә кирәк. Нинди генә вазыйфада булсаң да, кеше булып калу мөһим. Бу яктан безнең завод коллективы бик бердәм. Ничәнче еллар булганын төгәл хәтерләмим, шулай бер заман эшкә килсәм, завод капкасы төбендә бер төркем яшь эшче басып тора. Алар уку тәмамлаганнан соң, якын-тирәдәге хуҗаларда вакытлыча яшәп, бездә эшлиләр иде. Ул елны завод өчен тулай торак төзеп бетерделәр. Әмма кулланышка тапшырырга ашыкмадылар. Кызлар исә сумкаларын күтәргән дә: «Без бүген эшкә бармыйбыз, хуҗалар фатирдан чыгарды, яшәргә урын юк», – диләр. Әһә, мин әйтәм, тулай торакка ишарәли болар. Тик сиздермәдем. Үгетләп, заводка алып кердем дә җитәкчелеккә мөрәҗәгать иттем. Бер-ике көндә түбәле иттек яшьләрне. Заводта хуҗалык кирәк-яракларына кадәр ясап, атларга төяп озаттык. Тулай торактан әле дә сәлам бирүчеләр бар.

Эш – бер хәл, гаилә дә бар бит әле. Танышканда Легия апаның ире Айдар абый Казандагы 22 нче заводта эшли торган булса. Соңрак ул да дары заводына күчә. Бергә эшлиләр, балалар үстерәләр.

– Хәзер бала тәрбияләүче яшь әниләргә карап, безнекеләр ничек үскән икән, дип шаккатам. Улым Ленар балалар бакчасына киткәндә кызым Резидә икенче сыйныфта гына укый иде әле. Минем эш көне иртәнге сәгать җидедә башлана. Резидә көн саен энесен бакчага йөртте. Шөкер, балаларым без эшләгәнне күреп үстеләр. Алар турында бер генә начар сүз дә ишетмәдем, – ди әни кеше.

Резидә Романичева заводка әнисе киңәше белән килә. Моңа тамчы да үкенми ул. Бер урында төпләнеп эшли башлаганына да кырык ел инде. Ленар Мөхәммәтҗанов яшьтән үк спорт белән дә, хәрби юнәлеш белән дә кызыксына. Армиягә киткәч, Ярославль хәрби училищесына укырга да кереп куя. Тик тормыш сукмагы аны барыбер Казан дары заводына алып кайта. Махсус хәрби операция башлангач, Ленар хәрби бурычына тугры калып, завод эшчеләренә бронь бирелүенә дә карамастан, ил чиген сакларга китә. «Улым белән горурланам. Гел аралашып торабыз. Әле яңа гына фотолар җибәргән иде. Аларны коридордагы комод өстенә куйдым. Үткән-киткәндә гел карап китәм», – ди Легия апа.

Алагаем зур бер заводны Мөхәммәтҗановлар кебек гап-гади, шул ук вакытта лаеклы эшчеләре үзенчәлекле итә дә инде. Бу хакта «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна учреждениесенең 235 еллыгын билгеләп үткәндә Рөстәм Миңнеханов та әйтте. «Бүген предприятиедә 2,5 меңнән артык кеше эшли. Бу – үз эшенең осталары, алар эшкә зур җаваплылык белән карыйлар. Ветераннарга аерым рәхмәт. Алар – хезмәт традицияләренә нигез салучылар. Ветераннарның осталыгы һәм тәҗрибәсе яшь хезмәткәрләргә күчә», – диде Рәис. Бәйрәм көнне бәйрәм теләкләрен кабул итүчеләр арасында Легия Мөхәммәтҗанова да бар иде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Казан дәүләт казна дары заводы – оборона-сәнәгать комплексы предприятиесе. Ул Екатерина II Указы белән 1788 елда оеша. Еллар дәвамында берничә тапкыр исемен үзгәртә. Әмма асылы шул ук кала – Ватан хакына хезмәт итәләр. Бүген ул – күп юнәлешле оешма. Биредә шул исәптән махсус һәм гражданлык продукциясе җитештерелә. Заводта барлык төрдәге ату һәм артиллерия кораллары, спорт-аучылык патроннары өчен төтенсез дарылар һәм шартлаткыч матдәләр эшләп чыгарыла.

«Безгә эшчеләр кирәк»

Татьяна МИХАЙЛОВА,
Казан дәүләт казна дары заводының кадрлар сәясәте идарәсе җитәкчесе:

– Сәнәгать җитештерү күләме арту сәбәпле, заводка хезмәткәрләр таләп ителә. Безгә төп һәм ярдәмче эшчеләр кирәк. Хәзерге вакытта 120 эш урыны бар. Болар – сәнәгатьнең төрле этапларына бәйле белгечләр. Мәсәлән, аппаратчылар, пресс ясаучылар, махсус эшләнмәләрне җыючылар. Эшкә урнашу өчен урта белем дә җитә. Яңа белгечләрне заводтагы укыту үзәгендә әзерлибез. Эшкә килергә теләүчеләргә төп шарт – аларга 18 яшь тулган булырга тиеш. Бу заводның җитештерү үзенчәлекләренә бәйле. Укыган вакытта хезмәт хакы – 45 мең сум, укып бетергәч – 50 мең сум һәм аннан да күбрәк тәшкил итә. Яшь эшчеләргә, техникум һәм көллиятләрне бетереп килүчеләргә беелдан өч ел дәвамында ай саен 4500 сум күләмендә өстәмә түләү дә гамәлгә керде. Яшь белгечләргә бу акча моңа кадәр дә бар иде инде. Июньгә алынган мәгълүматларга караганда, заводта уртача хезмәт хакы, җитәкче вазыйфаларын исәпкә алмыйча, 80 мең сум тәшкил иткән. Айлык акчадан тыш, предприятие торакны арендалауга киткән акчаны өлешчә компенсацияли, ашау өчен түли, сөт бирә. Зыянлы эштә эшләүчеләргә өстәмә ял һәм пенсиягә иртәрәк чыгу хокукы (хатын-кызларга – 7,5 ел, ир-атларга 10 ел эшләргә кирәк) да бирелә. Хезмәткәрләрнең балаларына да күп төрле ярдәм чаралары каралган. Мәсәлән, бәби алып кайтучыларга бер тапкыр 3 мең сум күләмендә акча түләнә, яшь әтигә бер көн түләүле ял бирелә. Төгәл мәгълүматны 554-34-51 телефон номеры аша алырга мөмкин.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең хуҗалык һәм транспорт тәэминаты хезмәте автотранспорт цехының автомобиль йөртүчесе (административ-идарә персоналына хезмәт күрсәтү буенча) **Бегов** Эмиль Раушан улына; Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары **Гафиятуллин** Мөнир Минхәйдәр улына; «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең «Семь дней» телевидение иҗат берләшмәсе махсус хәбәрчесе **Дәүләтшин** Зөфәр Вахит улына; «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең «Семь дней» телевидение иҗат берләшмәсе телеоператор-постановщигы **Ключников** Андрей Валентиновичка; «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» филиалы массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге башлыгы – шеф-редактор **Угаров** Алексей Евгеньевичка; «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ультратавыш ярдәмендә диагноз куючы табибы **Җиһаншин** Илшат Гали улына; «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең физик культура һәм спорт фәнни-тикшеренү институты медицина-санитария часте башлыгы **Янышева** Гөлнара Гомәр кызына; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты **Лазарев** Павел Сергеевичка; «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Нәүмәтова** Гөлназ Шәүкәт кызына; 2129-П гаскәри часте хәрби хезмәткәре **Пырков** Дмитрий Александровичка; 2129-П гаскәри часте хәрби хезмәткәре **Симонов** Артём Алексеевичка; шәхси эшкуар «Басырова Лилия Нурсаяф кызы» **Басырова** Лилия Нурсаяф кызына; «Татавтодор» акционер җәмгыяте Апас филиалының «Кама Тамагы» юл төзекләндерү-төзелеш участогы асфальт-бетон заводы операторы **Гумиров** Камил Замил улына; «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәтләндерү транспорты дирекциясе структур бүлекчәсе – Горький хәрәкәтләндерү транспорты дирекциясе структур бүлекчәсе – Юдино локомотивларны эксплуатацияләү депосының тепловоз машинисты **Җамалиев** Алмаз Азат улына; «СтройТраст» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Минегалиев** Раил Габдулхай улына; «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте нефть эшкәртү заводының товар-чимал производствосы башлыгы урынбасары **Миронов** Евгений Владиславовичка; «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең техник хезмәт күрсәтү һәм электр җиһазларын төзекләндерү хезмәте гидрирлау (каталитик крекинг) һәм күкерт-кислота алкидлаштыру продуктларын эшкәртү цехының газларны фракционлаштыру җайланмасы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү электромонтеры **Попов** Денис Николаевичка; «Татшина» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте проект офисы белгече **Смышляев** Александр Валентиновичка; «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең техник хезмәт күрсәтү һәм технологик җиһазларны төзекләндерү хезмәте күкертле нефтьне крекерлау һәм аннан нефть продуктлары эшләү (гидрокрекинг, майлар җитештерү) цехының технологик җиһазларны төзекләндерү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү участогы мастеры **Хәкимов** Алмаз Хөсәен улына; «Түбән Кама шин» гавами акционер җәмгыяте җыю цехының покрышкалар җыючысы **Шәрипов** Мәсхут Госман улына; «Бильданов Рәфкать Рифат улы» шәхси эшкуары **Бильданов** Рәфкать Рифат улына; «Рубин» футбол клубы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төп командасы футбол буенча спортчы-профессионаллары: **Дюпин** Юрий Юрьевичка, **Иванов** Олег Александровичка, **Мартынович** Александр Владимировичка, **Рахмоналиев** Умарали Мөхәммәдали улына; «Рубин» футбол клубы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төп командасы баш тренеры **Рәхимов** Рәшид Мәмәткол улына; хезмәт ветераны **Мачтаков** Леонид Яковлевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

ҖЫРЛА, МИРСӘЕТ!

Юбилей

Әлки төбәгеннән сөенечле хәбәр килеп ирешә. Якташларының теләген исәпкә алып, район үзәге Базарлы Матак авылының яңа урамына Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Мирсәет Сөнгатуллин исеме бирелгән.

Ул туып-үскән Әлки районы Татар Борнае авылы табигатьнең гүзәл бер почмагына урнашкан. Борынгы Болгар төбәгенең инеш-күлләренә, әйләнеп чыккысыз урманнарына сыенып яшәүче бу авыл үзенең уңган кешеләре, төрле һөнәр осталары белән дан тота. Ә менә халкыбызның үзәкне өзәрлек моңлы җырларын бөтен нечкәлекләре белән башкаручы мәшһүр талант ияләре Рәшит Ваһапов, Габдулла Рәхимкулов, Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев традицияләрен дәвам иттерүчеләр күп түгел. Андыйлар берничә гасырга бер туа бугай.

Хәер, Әлки төбәге талантлы шәхесләре белән хаклы рәвештә горурлана ала. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Галия Булатова, танылган шагыйрьләр Нәби Дәүли, Шамил Маннапов, чуаш халкының классик шагыйре Педер Хузангай, танылган артистлар Исламия Мәхмүтова, Рузия Мотыйгуллина, Әсхәт Хисмәтов, Резедә Төхвәтуллина һәм башка талант ияләре белән ничек горурланмыйсың ди?! Әмма халкыбызның яраткан җырчысы Мирсәет Сөнгатуллин арада аерым игътибарга лаек. Аның башкаруындагы 205 халык җыры тупланган кассетаның Гиннесснның рекордлар китабына керүе дә шуны раслый.

Бу җәһәттән берничә ел элек булган бер очрашу хәтердә. Без, 1974 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлап, дөньяның төрле почмакларына таралган 495 нче төркем вәкилләре, биш ел саен Казанда узучы чираттагы очрашуга җыелдык. Арада кемнәр генә юк: «Российская газета» редакциясе баш мөхәррире Владислав Фронин, Молдова дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитеты җитәкчесе Александр Дороган, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, Мәскәүдә нәшер ителүче хәрби журнал редакторы, полковник Михаил Земсков, «Мир бизнеса» журналы редакторы Алсу Бикбаева һәм башкалар, кыскасы, гомерләрен иҗатка багышлаган кешеләрнең сөйләшер сүзләре көн буена гына сыймыйча, таңга кадәр дәвам итте.

Александр Дороган очрашуга бүләк итеп берничә китабын һәм үзе белән бер мәктәптә укыган танылган җырчы София Ротаруның утызлап халык җыры тупланган яңа кассетасын алып килгән. Танылган җырчы әлеге хезмәте өчен Молдова Республикасының иң югары дәүләт бүләкләренә лаек булган.

Мин үз чиратымда якташым Мирсәет Сөнгатуллинның ике йөздән артык җыр кергән кассетасы белән мактанып алдым. Мондый хезмәтнең бүгенгә кадәр тиешенчә бәяләнмәве турында гына әйтмәдем.

Ә бит кассетага тупланган җырларның һәркайсында Мирсәет Сөнгатуллинның күңел җылысы, иҗади эзләнүләре, халкыбыз җырларын үз итүчеләрнең күзеннән яшь китерүче гаҗәеп моң ята. Халкыбызның борынгыдан килгән илаһи аһәңен йөрәге аша үткәреп, башкаларның күңеленә сеңәрлек итеп, бөтен җанын-тәнен биреп башкармаса, әлеге җырлар бу кадәрле тәэсир итә алыр идеме? Иманым камил: әгәр дә ул җырлар гади инструментлар аша гына түгел, ә симфоник оркестрга кушылып башкарылса, дөньякүләм танылу да алыр иде.

Мирсәет белән якыннан танышып-аралашу Казанда дәвам итте. Ул чорда «Социалистик Татарстан» газетасында хатлар бүлеге мөдире булып эшләүче авылдашыбыз Сәмигулла Хәйретдинов сәләтле якташларны үз янына туплап яшәргә омтылды. Газетага язылу эшен оештыручы буларак Сәмигулла абый безне әледән-әле укучылар белән очрашуларга да чакыра. Ул вакытларда газетаны Россиянең барлык төбәкләрендә яратып укыйлар иде. Очрашуларга зал тулып халык җыела. Сөйләшеп туйганнан соң, рәхәтләнеп җыр тыңлыйбыз. Танылып кына килүче Мирсәетне озаклап кул чабып, сәхнәгә кабат-кабат чакыралар. Ә ул исә һәр яңа очрашуга яңа җыр әзерләп килә. Ул елларда газетаның тиражы 200 мең данәдән артып китүе дә шундый ихлас очрашулар нәтиҗәсе түгел идеме икән әле?

Якташыбыз Сәмигулла Хәйретдинов чираттагы командировкага барган җиреннән 47 яшендә йөрәк өянәгеннән мәрхүм булгач, ел саен диярлек аны искә алырга җыелабыз. Очрашуларның үзәгендә – Мирсәет Сөнгатуллин. Гомер бик тиз уза. Күптән түгел якташыбызның 75 яшьлеген билгеләп узарга уйладык. Хезмәттәшләрем – «Ватаным Татарстан» газетасы журналистлары һәм җырчы Мирсәет Сөнгатуллин ерак Спас районы Иске Рәҗәп авылына юл алдык.

Юлда барганда әллә ниләр турында сөйләшелә. Тик ни турында гына сөйләшсәк тә, үзебез дә сизмичә, сүзебез җырга-моңга барып тоташа.

– Моңга сусауның ни икәнлеген чит илдә аңлый башладым. Мәктәпне тәмамлап, бер ел ташчы һөнәрен үзләштергәннән соң, армия хезмәтен Чехословакиядә узарга туры килде. Бәйрәм концертында Габдулла Тукайның «Тәфтиләү» җырын башкардым. Татарлар, башкортлар җырны бик җылы кабул итте. Иң гаҗәбе – концерттан соң часть командиры чал чәчле полковникның мине якын туганыдай кочып алуын мәңге онытасым юк. «Тәфтиләү» мәрхүм әнисенең яраткан җыры булган икән, – дип искә ала Мирсәет.

Якташларыбыз арасында Мирсәет Сөнгатуллин кебек җырчының булуы – үзе бер бәхет. Нинди генә очрашу яки истәлекле вакыйга булмасын – ул кирәк! Чираттагы очрашуга чакыргач, бөтен эшен ташлап, юлга чыктык. Сөйләшә-сөйләшә барып, озын-озак юл сизелми дә үтелде.

Кайсы авыл аша гына узмыйк, юлдашым нинди дә булса истәлекле вакыйганы искә ала.

– Җәй көннәрендә җәяүләп әнинең туган авылы Яңа Рәҗәпкә барышлый, урман-кырларда туктап, җырлап карый идем. 25 чакрым ара бит. Биш чакрым үтәм дә җырлап алам. Ашыйсы килү дә онытыла. Өстәвенә кошлар да миңа кушылган сыман. Урманда җыр да матуррак яңгырый.

Авылда радио барлыкка килгән заман. Гөлсем Сөләйманованың моңлы тавышын ишеткәч, озак тынычлана алмадым. Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Рәшит Ваһапов, Таһир Якуповның җырларын бүген дә тыныч кына тыңлый алмыйм. Күңелемнең иң нечкә кылларына чиртәләр сыман. Җыр бит ул җанга рәхәтлек биреп кенә калмый, тирә-яктагы матурлыкны күрергә өйрәтә. Моң исә үзенә күрә бер сихри көчкә ия...

...Дөньяның татарлар күпләп яшәгән төрле илләрендә, Россия төбәкләрендә узган һәр очрашу турында истәлек язмалары алтын бөртекләр булып Мирсәетнең көндәлегенә теркәлеп бара икән. Үзе башкарган татар халык җырлары турында тупланган мәгълүматлары да зур бер фәнни хезмәткә тиң. Кызыклы очрашулар, гыйбрәтле хәлләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре китап булып үз укучысына барыр вакытын көтә.

Юлда вакыт тиз үтә. Бигрәк тә юлдашың сүзгә саран булмаса. Шушы кыска гына сәфәр вакытында юлдашым турында әллә никадәр мәгълүмат алдым. Гади генә авыл егетенең шактый катлаулы юл үтеп, Мәскәүдә «Бәйрәм» ансамбленә нигез салуын, мәшһүр җырчыбыз Әлфия Авзалованың хәер-фатихасы белән Мәскәү кызы Кадрия белән тормыш коруын, аннары инде Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев ярдәме белән Казанга кайтуын белдем. Бу еллар эчендә үзенең армас-талмас тырышлыгы, таланты аша халкыбыз күңелендә иң югары бәя алган моң иясен Болгар якларындагы Иске Рәҗәп авылында кочак җәеп каршы алдылар. Хәер, кая гына барса да, ул – күптән көтелгән кунак. Яраталар, зурлап хөрмәт итәләр Мирсәет Сөнгатуллинны.

Камил СӘГЪДӘТШИН

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Төссезлек тантанасы

Төн җитмәгән әле, кояш батып, эңгер генә иңгән. Күз бәйләнә бара. Тирә-юньдәге бөтен нәрсә асыл төсен җуеп, соры булып күренә. Бөтен төсләрне бергә кушып бутаганнар да шуннан уртача бер нәрсә барлыкка килгән шикелле – нинди төс икәнен дә чамаларлык түгел. Төссез бер төс инде шунда…

Авылның әллә нинди дәртле чаклары булган ул. Әле без бәләкәй чакларда да көн саен диярлек ниндидер яңалык чыгып тора, телдән телгә күчеп, мизгел эчендә тарала, өлкәннәрне «Кит аннан! Булмас ла…» – дип, тел шартлатырга мәҗбүр итә торган иде.

Сәгъдәт дигән бер абзый була торган иде. Салырга ярата яратуын, әмма үзе ут кебек: җитмәгән җире, эшләмәгән эше юк. Кылмаган юләрлеге дә юк иде бугай. Алма бакчасына төшкәнебезне күреп калгач, ул хәтта безне дә: «Менә пычак, хәзер суям», – дия-дия, учын-учка ышкый-ышкый, урам буйлап куып йөргән иде. Пычагы юклыгын белсәк тә курыктык ул вакытта. Менә шул абзый бер язны күршеләренең агач ботагын кисәргә дип менгән. Ул кадәр биеккә үрмәләргә берәүнең дә йөрәге җитмәс иде, ә бу менеп киткән. Кул пычкысы белән ботакны кискән уңайга урамнан узучыларга кычкырып утыра икән. «Фәлән түткәй, хәлләр ничек! Саескан сыман гына күренәмме?» – дигәнен кызык күреп сөйләп тә йөрделәр әле. Җырлап та ала икән үзе: «Ала карга дигән, ай, асыл кош Агач башларына ник кунган…» Шул рәвешле үзен кошка тиңләп утыра торгач, бер мәлне очып та төшкән. Җиргә дә түгел хәтта, койма тактасына биле белән эләккән.

Авыл халкы аһ итте инде. Кызгандылар, аннан да бигрәк шулкадәр биек агач башына менә алуына аптырадылар. Без, малайлар, соңыннан махсус барып карадык – ул кадәр биеклеккә хәтта без дә менәргә шүрләр идек. Анда кадәр менеп җитә алсак, чынлап та үзебезне кош сыман тояр идек. Бу бит әле балта-пычкысын тоткан килеш менгән. Хәйран калырлык бар.

«Үләр инде, я гарипләнеп калыр», – дип борчылышты авыл халкы. Ә бу бер атна үтүгә кайтып төште дә баскан җирендә тузан уйнатып йөри башлады.

Икенче бер абзый колхоз бозавын урлап тотылды. Бу хакта ишеткәч, авыл халкы чынлап та тел шартлатып, башын чайкарга мәҗбүр булды: «Кит аннан, агай! Булмас. Ул кешенең сукыр бер тиененә дә тия торган адәм түгел бит!» Каршы төшүчеләр дә табылмый калмады: «Кешенекенә, бәлки, тимәс иде. Ул бит колхозныкына тигән. Төнлә. Беркем күрмәгән чакта…»

Тикшерә торгач, ачыкланды бугай барысы да. Бу эштән кайтышлый сыерлар җәйләве янындагы буага балыкка барган да соңга калган. Җәяүләп кайта-кайта караңгыга калган. Елга буйлап барганда, су уентыгындагы сазлык сыман урында чыпылдап яткан җан иясен күреп калган. Бозау көтүе сулауга төшә торган урын инде бу. Теге җан иясенең бозау икәнен белгәч, бер дә уйлап тормыйча, шунда кереп киткән. Көч-хәл белән сөйрәп чыгарган моны. Бозау ярга чыккан да хәлсезләнеп егылган. Нишләргә хәзер? Калдырып китсәң, ерткыч-җанварга эләгүе бар. Күтәреп йөртерлек түгел. Җәйләү дә, ферма да әллә кайда ук. Елга ярындагы таллардан арата шикелле нәрсә ясаган да бозауны шунда салып, өенә сөйрәп алып кайткан. Һәм бозау урлаучыга әйләнгән.

Мондый хәлләрне сөйли башласаң, бик озакка китәр иде. Әлегә җитеп торыр. Элекке кеше «энергичный» булган дип әйтәсем генә килә, дәрте-дәрманы ташып торган аның. Бер нәрсәгә дә битараф кала алмаган.

Хәзер алай түгел бугай. Һәрхәлдә, бүген мин бөтен авыл буйлап эзләсәм дә, фәлән метр биеклегендәге агач башына менеп, ботак кисәрлек сыңар адәм дә таба алмаячакмын. Күбесе менә алмый, менә алганы иренә, үзенә кирәкмәгәч, юкка көч түгәргә теләми. Ә елга уентыгындагы сазлыкта чәбәләнеп яткан бозауны коткару өчен төнлә түгел, көндез дә ләмле суга кереп китми хәзерге кеше. Беренчедән, ул аны күрми уза. Күрсә дә, игътибар бирми, игътибар бирсә дә, суга керми. Колхоз малын коткарам дип, үзенең дә батып үлүе бар чөнки. Кызганмый ул аны. Хәзерге кеше белән хис-тойгы түгел, исәп-хисап идарә итә.

Мин менә элекке абзыйларны искә төшереп карыйм да… Төрлесе төрле кеше аларның, мактаулылары да, яманаты чыкканнары да бар. Ләкин аларның һәркайсы үзенчәлекле, дәртле, энергиясе ташып тора торган кешеләр булган. Һәркайсы – кабатланмас шәхес. Хәзер андыйлар бармак белән генә санарлык. Бернинди калыпка да сыймыйча, ут уйнатып яши торган кешеләр юк. Булса да сирәк. Әллә без күрмибез, әллә үзләре күзгә чалынмаска, бүтәннәр кебек үк булып күренергә тырыша.

Без ничектер бертөрлерәк бәндәләргә әверелеп беттек бугай. Бер үк төрле фикер йөртәбез, бер үк сүзләр сөйлибез, бер үк эшләр эшлибез, бер үк төрле яшибез. Күбрәк мөлкәт тупларга, тормыш шартларын җайларга, проблемаларны юк итәргә тырышып гомер итәбез дә ахыр чиктә үзебез бер проблемага әйләнәбез. Нәкъ менә эңгер ялмап алган дөнья сыман. Барыбызны да бергә кушып бутаганнар да шуннан ниндидер бер соры кавем килеп чыккан – нәрсә икәнен дә чамаларлык түгел. Төссез бер төс… Кешелексез кешелек…

Гел генә болай булмас инде ул. Кайчан да булса йолдызлар да кабат үз урыннарын алыр… Кояш та чыгар… Ләйсән яңгыр явып китәр дә салават күпере пәйда булыр… Дөнья мең төсләргә кереп балкый башлар.

Ә әлегә… Мин эңгердә яшим…

Төссезлек тантана итә.

«ИЛГӘ ТЫНЫЧЛЫК ТЕЛӘП ҮРӘБЕЗ»

БИКЛӘН АВЫЛЫ ХАЛКЫ ФРОНТКА БУЛЫША

Ватан хакына

Тукай районының Бикләν авылында пенсия яшендәге апалар атнага биш тапкыр китапханәгә йөри. Юк, китап укырга түгел, хәрби операциядә катнашучы егетләргә булышырга. Башта оекбаш бәйләсәләр, хәзер окоп шәмнәре ясыйлар, маскировка челтәрләре үрәләр. 43 челтәр үреп фронтка җибәргәннәр инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Без килгәндә, китапханә ишек төбендә велосипедлар өелеп тора иде. Әллә мәктәп яны лагерена йөрүче балаларныкымы дисәк, апаларныкы булып чыкты. Бераздан самокатта элдереп, 70 яшьлек Саймә апа Рәхимова килеп җитте. Мең йортлы авыл булгач, тиешле урынга тиз генә килеп җитәм димә, шуңа күрә «техника» иярлиләр. Иртәнге 9дан кичке 4кә кадәр бертуктаусыз эшли алар. Җитезләр, куллары кулга йокмый. Кайбер көнне 15–20 кеше җыелса, кайчак 5–6 була икән. Ватан өчен дип тырышкан ханымнар кайвакыт өйдәгесен дә онытып җибәрә. Хәзерге вакытта авылдан 11 егет хәрби операциядә катнаша. Алар барысы да бер тапкыр ялга кайтып киткән инде.

– Авыл халкы бик бердәм, – ди әлеге эшне оештыручыларның берсе Фирия Гарипова. – Без башта медицина кирәк-яраклары алырга халыктан 29 мең сум акча җыйдык. Аннан солдатларга киемнәр, йокы капчыклары, жилетлар (разгрузочный) алдык. Үзебез җеп эрләп, җылы оекбашлар бәйләдек. Черки, талпаннардан саклану чаралары да сатып алабыз. Апрельдән маскировка челтәрләре бәйләргә тотындык. Алар техника, окоплар өстенә ябу өчен кирәк. Без башта челтәр өчен кирәк-яракларны әзерләп, Новотроицк, Круглое Поледа урнашкан гуманитар ярдәм пунктына илтеп тапшырдык. Шундагы кызлар: «Әйдә сез дә бәйләгез», – диделәр. Башта куркып кына башлаган идек. Әмма хәзер авырлыгын сизмибез. Чаллыга барып, мастер-класс үтеп кайттык. Озынлыгы – 6га 3 метр. Бер стандарт буенча бәйлибез. Бер көндә эшләп бетергән чаклар да бар. Гадәттә ике көн кирәк. Аның кышкы һәм җәйге төрләре бар. Җәйгә яшел төслесе кирәк. Шуңа күрә без аларны мандык. Розалия Хәйдәрова мунчасы кыш көне буяу цехына әйләнде. Хәния һәм Тәлгать Фәизовлар белән Мөнирә һәм Фред Әхмәтвәлиевләр шәмнәр дә ясый. 400 кило чималдан әзерләделәр.

Китапханә чын-чынлап цехка әйләнгән. Монда кешенең бер-берсе белән сөйләшергә дә вакыты юк. Кемдер кисә, кемдер үрә. Һәркем үз эшен белә, кушып торасы юк. Кисәргә махсус машина алганнар. Апаларның бөтенесе дә үзләре теләп йөри. Иң олысына – 70 яшь.

– Эшебезне илгә тынычлык теләп, башка үрергә язмасын дип башкарабыз инде. Әмма гел сорап торалар шул, – ди Мөнирә апа Әхмәтвәлиева.

Хәрби операциядә катнашучыларга булышучылар арасында улы мобилизацияләнгән Алсу Бәдертдинова да бар. Без барганда, улы Фәрит ялга кайткан иде. Дөресрәге, башы яраланган егет Чаллыдагы госпитальдә дәвалана иде. Әнисе әйтүенчә, улы иптәшләре янына барырга ашкынып тора икән. Гаиләсе дә бар югыйсә. Әмма 35 яшьлек Фәрит фронтта үзенең кирәклеген тоя. Заманында Грузиядә «кайнар нокта»да булган. Анда Жуков медале белән бүләкләнгән.

– Фронтка бергәләп ярдәм итәргә тырышабыз. Улым кайткач, бөтен авыл булышты, берәү дә читтә калмады. Кемдер акчалата, кемдер ризыклата. Барысына да исән-сау әйләнеп кайтырга язсын, – ди Алсу ханым.

Бикләν халкы 23 февраль алдыннан егетләргә унар мең сум акча җибәргән. Гаиләләрен чакырып, мәчеттә Коръән укытканнар. 8 Март бәйрәменә хәрби операциядә катнашучы егетләрнең әниләрен, хатыннарын җыйганнар. Уразадан соң фитыр сәдакаларыннан да өлеш тигән. Кыскасы, авыл халкы аларны авыр чакта ялгыз калдырмый.

Розалия Миннегалиева финанс чыгымнары өчен җавап бирә. Без килүдән файдаланып, ул да үзенең гозерен җиткереп калырга тырышты.

– Халыктан акча күбрәк җыелган саен, ярдәм итү мөмкинлеге дә арта. Без «Инеш», «Русал» кибетләренә ярдәм тартмалары куйган идек. Анда консерв, бозылмый торган ризыклар, кырыну җайланмалары һәм башкасын салалар. Авыл халкы актив. Әмма бу тартма турында белеп бетермәгән кешеләр дә бар. Теләгәннәр шунда сәдака сала ала. Тагын берничә кибеткә куячакбыз, – ди Розалия ханым.

Игелекле апалар егетләрне төрлечә сөендерергә тырыша. Челтәрләр, киемнәр тутырылган капчыклар эченә тәмәке, көнбагыш, кәнфит, салфетка тыгып, күчтәнәч тә җибәрә. Үзләренчә, көтелмәгән булсын әле, диләр. Сернең капчыкта ятмаганы да бар. Капчыкларга «Без сезнең җиңеп кайтуыгызны көтәбез. Сез – җиңелмәс солдатлар, илнең кадерле уллары» дип язылган. Бу сүзләрдән барысы да аңлашыла. Тизрәк әйләнеп кайтыгыз, егетләр!

Сәрия МИФТАХОВА

ЙОМЫРКА БӘЙРӘМЕ

БЫЕЛ «СКОРЛУПИНО» БӨТЕНРОССИЯ ФЕСТИВАЛЕ ЯҢА ФОРМАТТА УЗАЧАК

Илнең 15 төбәге, 40 меңгә якын кунак, 5 рекорд. Узган елларда Питрәч районында «Скорлупино» Бөтенроссия фестивале әнә шулай узган. Җиденче тапкыр үткәрелүче традицион фестиваль Питрәчтә 30 июльдә гөрләячәк. Күпләр яратып өлгергән йомырка бәйрәме быел нәрсәләр белән шаккатырыр?

«Татар-информ»

– Республиканың төрле районнарында узучы җирле үзенчәлекле фестивальләр «Скорлупино»дан башланды. Әйтик, Мамадыштагы «SUNNY ФЕСТ» креатив чаналар фестивале, Әгерҗедәге «Бал бәйрәме». Җиде ел эчендә фестивальдә Россиянең 15 төбәгеннән 40 меңгә якын кунак катнашты, 5 рекорд куелды, шуларның берсе Россия рекордлар китабына кертелде, – дип сөйләде матбугат очрашуында Татарстан яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Сабирова.

Питрәч районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Альберт Сабитов әйтүенчә, быел чараның форматы һәм эчтәлеге үзгәргән.

– Хәзер тенденцияләр үзгәрә. Элек «Скорлупино» яшьләр Сабан туе форматында булса, без моннан читкә китәбез, хәзер ул – патриотик чара. Без яши торган заманда бу мөһимрәк, – диде Альберт Сабитов.

Фестивальнең оештыручысы Наилә Таҗиева сүзләренә караганда, быел халык мәдәниятен, гореф-гадәтләрен үстерүгә һәм популярлаштыруга зур басым ясалачак.

– Фестиваль элек тә патриотик рухта узды. Чөнки бу үз җиреңә мәхәббәт тәрбияләү, районыңны күтәрү, яшьләрне кече Ватаннарын үстерүгә җәлеп итү. Форматны үзгәртү ул – заман таләбе. Хәзер күңелле уеннар уздыру бик урынлы булмас иде. Быел төбәк тарихы турында сөйлибез, районның мәдәни картасын төзибез. Яшьләрне халкыбызның тарихын өйрәнүгә күбрәк җәлеп итәргә телибез, – диде Наилә Таҗиева. – Фестивальнең барлык кунаклары өчен квест булачак. Авылларыбыз, районыбызның танылган кешеләре, истәлекле урыннары турында сөйләячәкбез. Фестивальдә Питрәч районының иң танылган кешесе – шагыйрь-мәгърифәтче Мәүлә Колыйга да зур урын бирелгән.

Фестиваль кунакларын Россия төбәкләреннән килгән осталар һәм һөнәрчеләр ярминкәсе каршы алачак. Традицион мәйданчык «Ско-ко – парк»та быел кош токымнарыннан тыш, төрле йорт һәм экзотик хайваннар да тәкъдим ителәчәк.

«Скорлупино» фестивале гаҗәпләндергеч рекордлар куюы белән билгеле. Быел да биредә ике яңа рекорд куелачак. Узган елларда рекордлы йомырка тәбәсе, торт пешерсәләр, быел авырлыгы 2 тоннадан артык тракторны тизлеккә һәм ераклыкка тарту белән иң зур әйлән-бәйлән ясау булачак.

– Әйлән-бәйләндә Татарстанда яшәүче иң күп милләт вәкилләре катнашачак. Уңай энергия белән алмашу һәм бердәмлектән тыш, бу – гражданлык позициясе дә, – диде Наилә Таҗиева.

Фестиваль яңалыклары моның белән генә бетми. Быел «Скорлупино»ның иң мавыктыргыч конкурсларының берсе – таба белән йөгерү ярышларының номинацияләрен арттырганнар. Быел ярышларга фестивальнең яшь кунаклары да кушылачак. Ярышлар йорт хуҗабикәләре образында узачак.

Җыр-биюләрдән тыш, бәйрәм кунакларын кызыклы конкурслар, йомырка ыргыту буенча чемпионат, фото-зоналар, мастер-класслар, ярышлар көтә. Кунаклар алдында «Bravometehi» һәм «Закария» фолк-төркеме, яшьләр өчен популяр этно-эксперименталь музыкаль DJ проект «ABIEMProjekt» чыгыш ясаячак. Концерт программасы Татарстанның атказанган җырчысы Илсөя Бәдретдинова чыгышы белән тәмамланачак.

Ләйсән САФИНА

Өч мең чакрым

ТАТАР АТЛАРЫ АЛТАЙГА ЮЛ ТОТТЫ

Чыдам, үҗәт һәм әрсез – татарның үзе кебек! Бу сүзләрне истә тотып, татар токымлы атлар зур сәфәргә чыкты. 38 көн эчендә өч мең чакрым юл үтеп, аларны Алтай Республикасына бүләк итеп калдырмакчылар. Бу зур сәфәрнең максаты нидә? Татарстан белән Алтай арасын тагын кемнәр узачак? Без шуларны белештек.

Бик озаклап һәм яхшылап әзерләнеп, махсус машиналарга печән, ашлык һәм су тутырып, 24 июльдә Казаннан кузгалган атлар кәрваны әлеге язма әзерләнгән вакытта Минзәлә районына барып җиткән иде инде. Аңа кадәр Питрәч, Теләче, Балык Бистәсе, Мамадыш, Алабуга, Тукай районнарында туктап, ял итәргә өлгергәннәр. Актаныштa да туктап, республика чиген узуга, Башкортстан, Пермь крае, Свердлау, Төмән, Омск, Новосибирск өлкәләре буйлап Алтай крае һәм Алтай Республикасына таба юл алачаклар. Ахыр чиктә кәрван Алтайның Майма районында – «Алтай – Евразиянең йөрәге» һәйкәле янында туктаячак. Сүз уңаеннан, әлеге һәйкәл – Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев бүләге.

Әлеге чарада катнашу өчен Лениногорск районыннан Нәбиуллиннар һәм Теләче районыннан Гыйниятуллиннар хуҗалыгыннан барлыгы алты татар аты сайланган.

– Аларны бит кирәк булганда гына өйрәтәсең, шуңа өйрәтелгәннәре аз. Әле аларны да шактый гына әзерләде малайлар. Сабан туйларында да чаптылар, болай да йөрттеләр. Аннан әле Казан ипподромында да әзерләделәр, – дип сөйләде безгә Сәгыйть Гыйниятуллин.

Бу зур сәфәрдә аның улы Фирзәр дә катнаша.

– Озын юл, дип тормады – китте. Ул оста бит инде. Хәер, анда киткән малайлар барысы да шундый.

Хәзерге вакытта Гыйниятуллиннар хуҗалыгында 200ләп баш татар токымлы ат бар икән.

– Бу чараның төп максаты – атларыбызны халыкка күрсәтү. Татар аты – татарның үзе кебек бит ул: чыдам, әрсез. Дөресен генә әйткәндә, атларыбызны Алтайга бүләк итү – яхшы нәрсә, әмма читтә үрчеткәнче, үзебездә җәелдерергә иде. Татарның үз аты булырга тиеш! Татар токымлы атны уйлап табасы юк – ул бар инде. Аларны күбрәк үрчетергә генә кирәк. Һәр районда ким дигәндә 5–6 фермер шуның белән шөгыльләнсә дә, таманга гына киләчәк. Ат чабышларында да аларны аерым җибәрә башларга кирәк, – ди Сәгыйть абый.

Атлар кәрваны бу озын юлны гел үзләре чабып кына үтмәячәк, билгеле. Күперләрдә, машиналар артык күп булган җирләрдә аларны махсус машиналар алып барачак. Алтайга, төгәлрәк әйткәндә, Карым авылына 25 августта барып җитәргә ниятлиләр. Атларын калдырган җайдаклар Казанга 30 август – 1 сентябрьдә кайтып җитәрләр дип өметләнәләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татар-информ»

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 306

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+